| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАДЕЖДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАДЕЖДИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 нче декабрь Надеждино авылы №12

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге территориясендә фейерверклар үткәрү өчен мәйданчыклар билгеләү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 19 нчы статьясына, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Надеждино авыл җирлеге территориясендә салютлар һәм фейерверклар оештыру һәм үткәрү, җәмәгать урыннарында пиротехник эшләнмәләрне куллануны, халыкның иминлеген, инфраструктура объектларын тәэмин итү, массакүләм чаралар үткәрүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Пиротехник чаралар (эшләнмәләр) куллану өчен мәйданчыклар билгеләргә (1нче кушымта).

2.Гражданнар тарафыннан көнкүреш пиротехника әйберләрен куллану буенча инструкцияне һәм белешмәлекне мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карарны Уставта билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Надеждино авыл җирлеге

Башкарма комитет җитәкчесе Е.В.Савельева

Надеждино авыл җирлеге
Башкарма комитетының
10.12.2019 елның 12 нче карарына
1 нче кушымта

Фейерверкларны җибәрү өчен мәйданчык Надеждино һәм Морат торак пунктлары арасында 200 метр арада урнашкан, көньякка 300 метр арада «Золотая Нива «агрофирмасы " ҖЧҖнең терлекчелек объектлары урнашкан. Мәйданчык янында биналар юк, төньяктан мәйдан кыр урнашкан.

